ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
КАМАЙ ТОРАК ПУНКТЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

20.11.2025 ел № 2

2026 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең Камай авылында гражданнарның үзара салым кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» » 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең Камай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2025 елның 7 ноябрендәге 4 нче номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең Камай авылының гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елда Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең Камай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту);

2. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, МАФ сатып алу, МТЗ-82.1 тракторы өчен чүмечле КУН сатып алу; МТЗ-82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу);

3. Урамнарны яктырту электр челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү (урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау);

4. Узган еллар акчаларының калган өлешен юлларны кардан чистартуга юнәлтергә.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтының http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Камай авыл җирлеге” бүлегендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге башлыгы ____________ И.М.Ахунҗанов